КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 15 гыйнвар г.Казань № 12

Урман тармагы өчен кирәкле белем бирү программалары буенча белем алучы югары белем бирү мәгариф оешмалары студентларына айлык стипендияләр рәвешендәге түләүләр турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урта һөнәри һәм югары белемнең уку-укыту программалары буенча максатчан уку турында» 2024 елның 27 апрелендәге 555 номерлы карары, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 1. Урман тармагы өчен кирәкле белем бирү программалары буенча белем алучы югары белем бирү мәгариф оешмалары студентларына ай саен түләнә торган стипендияләр рәвешендә һәр укучыга 2 056,0 сум күләмендә түләү билгеләргә (алга таба - студентларга стипендияләр) .

2. Карарга теркәлгән Урман тармагы өчен кирәкле белем бирү программалары буенча белем алучы югары белем бирү мәгариф оешмалары студентларына айлык стипендияләр рәвешендәге түләүләр бирү кагыйдәләрен расларга.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда студентларга айлык түләүләрне башкару өчен Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына акчаларны күздә тотарга.

4. Бу карарның гамәле 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 15 гыйнвар, 12 нче
карары белән расланды

## Урман тармагы өчен кирәкле белем бирү программалары буенча белем алучы югары белем бирү мәгариф оешмалары студентларына айлык стипендияләр рәвешендәге түләүләр бирү кагыйдәләре

1. 1. Әлеге Кагыйдәләр “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Урта һөнәри һәм югары белемнең уку-укыту программалары буенча максатчан уку турында” 2024 елның 27 апрелендәге 555 номерлы карары, “Мәгариф турында” 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнгән һәм урман тармагы өчен кирәкле белем бирү программалары буенча белем алучы югары белем бирү мәгариф оешмалары студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләр бирү механизмын һәм шартларын (алга таба - студентлар, стипендия) билгели.

2. Стипендия алу хокукына түбәндәге шартлар булганда студентлар ия:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы (алга таба - Министрлык) белән төзелгән максатчан укыту турындагы шартнамә нигезендә көндезге уку рәвеше буенча федераль бюджет акчалары исәбеннән югары белем бирү мәгариф оешмаларында уку;

максатчан уку турында шартнамәдә максатчан уку турында шартнамәдә күрсәтелгән Министрлыкның ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениесендә (алга таба - урман тармагы учреждениесе) югары белем бирү мәгариф оешмасында студент уку узган әзерлек (профиль) юнәлеше буенча кимендә өч ел эшләү йөкләмәсе булу;

салым органында алынган тиешле белешмә (алга таба - белешмә) белән расланган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурыч булмау (агымдагы елның 1 сентябренә һәм хисап елыннан килүче елның 1 гыйнварына). Белешмә Министрлыкка агымдагы елның
15 сентябренә кадәр һәм хисап елыннан соң килүче елның 15 гыйнварына кадәр студент тарафыннан тапшырыла.

3. Стипендия уку чорында бер тапкыр билгеләнә.

4. Министрлык ел саен, агымдагы елның 1 октябренә кадәр, хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр, югары белем бирүче мәгариф оешмаларының укырга керүе турында боерыклары (боерыкларыннан өземтәләр), белешмәләр нигезендә стипендияләр түләнәчәк студентлар исемлеген (алга таба - Исемлек) төзи.

5. Министрлык Исемлек нигезендә ай саен стипендияләр бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан урман тармагы оешмасына акча күчерә.

6. Стипендияләр түләү шушы максатларда каралган Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр акчалары исәбеннән ай саен башкарыла.

Урман тармагы учреждениесе акча кергән көннән алып 10 эш көне эчендә, әмма айның 25 еннән дә соңга калмыйча, студентларның кредит оешмаларында ачылган счетларына стипендия күчерәләр.

7. Стипендия түләве түбәндәге хәлләрнең берсе килеп чыккан очракта туктатыла:

студентны югары белем бирү оешмасыннан чыгару, шул исәптән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хезмәткә чакыруга бәйле рәвештә. Югары белем бирү оешмасында торгызылганда һәм максатчан укыту турындагы элегрәк төзелгән шартнамә нигезендә укытуны дәвам иткәндә, студент стипендия алуга дәгъва итәргә хокуклы;

студентка академик ял биргәндә. Академик ялдан кайткач һәм элегрәк төзелгән максатчан укыту турындагы шартнамә нигезендә укуын дәвам иткәндә, студент стипендия алуга дәгъва итәргә хокуклы;

студентны үзенең инициативасы белән максатчан укыту турындагы шартнамәгә туры килми торган укыту характеристикалары белән укырга күчерү;

Министрлыкка студент тарафыннан белешмәләрне үз вакытында тапшырмау.

8. Әлеге Кагыйдәләрнең 7 пунктының икенче - дүртенче абзацларында каралган шартлар барлыкка килгән очракта, студент, шартның барлыкка килү датасыннан бер айдан да соңга калмыйча, Министрлыкка раслаучы документны (документларны) теркәп, тиешле шарт барлыгы турында язма рәвештә хәбәр итә (алга таба - хәбәрнамә) .

Хәбәрнамәне, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срокта, югары белем бирү мәгариф оешмасы җибәрергә хокуклы.

9. Стипендия түләү әлеге Кагыйдәләрнең 7 пунктында каралган шартлар килеп чыккан айдан соң килүче айның 1 числосыннан туктатыла.

10. Студент булган һәм стипендия алган зат урман тармагы учреждениесе белән хезмәт килешүе төзелгән көннән алып җиде эш көне эчендә Министрлыкка эшкә урнашу фактын раслый торган белешмә тапшырырга тиеш.

11. Студент (студент булган һәм стипендия алган зат) максатчан уку турындагы шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәү сәбәпле максатчан уку турындагы шартнамә өзелгән очракта, аңа стипендия түләүгә бәйле чыгымнарны тулы күләмдә капларга тиеш:

белем бирү программасын үзләштерү буенча;

урман тармагы учреждениесенә эшкә урнаштыру;

максатчан уку турында шартнамәдә күрсәтелгән вакыт дәвамында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча.

12. Урман тармагы учреждениесе хезмәт шартнамәсен вакытыннан алда өзү һәм студент булган һәм стипендия алган затны эштән азат итү турында Министрлыкка азат ителү көненнән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә язмача хәбәр итә.

13. Министрлык әлеге Кагыйдәләрнең 11 пунктында күрсәтелгән максатчан уку турындагы шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәү сәбәпле максатчан уку турындагы шартнамә өзү датасыннан алып бер ай эчендә студентка (студент булган һәм стипендия алган затка) күрсәтелгән чыгымнарны исәпләү кушымтасы белән аңа стипендия түләүгә бәйле чыгымнарны каплау кирәклеге турында язма рәвештә хәбәр итә.

14. Студент (студент булган һәм стипендия алган зат) максатчан уку турында шартнамә өзелү датасыннан алып Татарстан Республикасы бюджетына аңа стипендия түләүгә бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында максатчан уку турында шартнамәдә билгеләнгән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган Министрлыкның шәхси счетына тулы күләмдә кире кайтара.

15. Студент (студент булган һәм стипендия алган зат) тарафыннан стипендия бирүгә бәйле чыгымнарны ирекле каплау вакыты бозылган очракта, урман тармагы учреждениесе мондый вакыт тәмамланганнан соң 10 көн эчендә бу хакта Министрлыкка язмача хәбәр итә.

Министрлык урман тармагы учреждениесе хәбәрен алынган көннән алып бер ай эчендә күрсәтелгән акчаларны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләтү чараларын күрә.

16. Бюджет акчаларыннан максатчан файдалануны тикшереп тору Министрлыкка йөкләнә.

___